СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**22 ноябрь 2018 ел** **№101**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 маендагы 90.1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турындагы Нигезләмәдә.

1) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.1 Үзара салым акчаларын җыю тәртибе башкарма комитет карары белән билгеләнә».

2) 5.2-5.4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп ур., 1б йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Носы авылы, Татарстан ур., 45 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов